МИНИСТЕРСТВО ПО ДЕЛАМ
ГРАЖДАНСКОЙ ОБОРОНЫ
И ЧРЕЗВЫЧАЙНЫМ СИТУАЦИЯМ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ГРАЖДАННАР ОБОРОНАСЫ
ЭШЛӘРЕ ҺӘМ ГАДӘТТӘН ТЫШ
ХӘЛЛӘР МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** г. Казань **БОЕРЫК**

17.06.2015 № 265

**Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгының дәүләт учреждениеләре белән бирелә орган түләүле уңайлыкларны күрсәтү тәртибен раслау турында**

Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгының (алга таба – Татарстан Республикасы ГТХМ) дәүләт учреждениеләре белән түләүле уңайлыкларны күрсәтү процедурасын, шул исәптән түләүле уңайлыкларны күрсәткән вакытта бәя билгеләү тәртибен һәм шартларын тәртипкә салу максаты белән б о е р ы к б и р ә м:

1. Татарстан Республикасы ГТХМ ның дәүләт учреждениеләре белән түләүле уңайлыкларны күрсәтү тәртибен расларга (Кушымта).

2. Татарстан Республикасы ГТХМ ның дәүләт учреждениеләренең җитәкчеләренә учреждениеләр белән күрсәтелә торган түләүле уңайлыклар исемлеген һәм шулай да һәр уңайлыкны күрсәтү тәртибен, шул исәптән расланган түләүле уңайлыклар өчен түләү тәртибе һәм шартлары нигезендә күрсәтелә торган бәя күләмен билгеләп кую буенча туры килә торган норматив хокук актларын китерергә.

3. Биредәге боерыкны үтәү контролен үземә калдырам.

Министр Р.Җ. Хәбибуллин

____________ № _______
Татарстан Республикасы ГТХМ
боерыгына кушымта

**Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгының дәүләт учреждениеләре белән бирелә орган түләүле уңайлыкларны күрсәтү тәртибе**

1. Гомуми кагыйдәләр

1.1. Биредәге Татарстан Республикасы ГТХМ дәүләт учреждениеләре белән түләүле уңайлыкларны күрсәтү тәртибе (алга таба – тәртип) түбәндәгеләр нигезендә эшләнгән:

- Россия Федерациясе Бюджет кодексы;
- Россия Федерациясе Салым кодексы;
- Россия Федерациясе Гражданлык кодексы;
- “Халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характерлы гадәттән тыш хәлләрдән саклау турында” 1994 ел 21 нче декабрь № 68-ФЗ федераль законы;
- “Гражданнар оборонасы турында” 1998 ел 12 нче февраль № 28-ФЗ федераль законы;
- “Россия Федерациясендә гражданнар сәламәтлеген саклау нигезләре турында” 2011 ел 21 нче ноябрь № 323-ФЗ федераль законы;
- “Россия Федерациясендә белем турында” 2012 ел 29 нчы декабрь № 273-ФЗ федераль законы;
- “Кулланучыларның хокуклары турында” 1992 ел 7 нче февраль № 2300-1 Россия Федерациясе законы;
- Татарстан Республикасы Бюджет кодексы;
- “Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау турында” 2004 ел 8 нче декабрь № 62-ЗРТ Татарстан Республикасы законы;
- “Белем турында” 2013 ел 22 июль № 68-ЗРТ Татарстан Республикасы законы;
- “Татарстан Республикасында гражданнар сәламәтлеген саклау өлкәсендә аерым мәсьәләләрне көйләү турында” 2012 ел 22 декабрь № 87-ЗРТ Татарстан Республикасы законы;
- “2015 елга Татарстан Республикасы учреждениеләре белән түләүле уңайлыкларны күрсәтүдән керем күләмнәренең планлы күрсәткечләрен раслау турында” 2015 ел 16 гыйнвар № 13 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары.

1.2. Биредәге Тәртиптә алдагы төшенчәләр кулланыла:

Учреждение – Татарстан Республикасы ГТХМ белән корып җибәрелә торган дәүләт учреждениесе;

Кулланучы – түләүле уңайлыкны ала торган физик яисә юридик шәхес.

1.3. Түләүле уңайлыклар сәламәтлек саклау, өстәмә профессиональ белем өлкәсендә халыкның ихтыяҗларын канәгатьләндерү, мәгълүматны эшкәртү буенча, уңайлыкларны үстерер һәм камилләштерер өчен өстәмә финанс чараларны тарту, материаль-техник җирлекне ныгыту максаты белән күрсәтелә.

1.4. Түләүле уңайлыкларны күрсәтү Учреждениенең финанс хуҗалыгы эшенең өлеше булыр.

1.5. Биредәге Тәртип түбәндәгеләрне билгеләп куя:

- түләүле уңайлыкларны бирү тәртибе;
- түләүле уңайлыкларның бәясен (тарифын) билгеләү тәртибе;
- түләүле уңайлыкларны күрсәтүдән керемнәрне планлаштыру һәм куллану тәртибе;
- түләүле уңайлыклар исәбен оештыру һәм түләүле уңайлыкларны күрсәтү буенча эш артыннан контроль.

## 2. Түләүле уңайлыкларның төрләре

2.1. Учреждениеләр күрсәтә торган түләүле уңайлыкларның төрләр исемлеге Учреждениенең уставында билгеләнә.

2.2. Учреждениенең уставта билгеләнмәгән уңайлыкларны күрсәтергә хакы юк.

## 3. Түләүле уңайлыклар бирүне оештыру

3.1. Түләүле уңайлыклар Учреждениеләр белән килешү һәм уңайлык түләнгәнне раслый торган түләү номеры һәм суммасы язылган документ нигезендә биреләләр.

3.2. Килешү яисә п. 3.1 дә язылган башка документ формасы законнарга туры китереп билгеләнә.

3.3. Түләүле уңайлыкларны күрсәткән вакытта биредәге Учреждениеләрнең билгеләп куелган эш тәртибе саклана, шул ук вакытта түләүсез нигездә күрсәтелә торган уңайлыклар киметелмәскә, аларның сыйфаты начарланмаска тиеш, шулай ук төп устав эше урынына яисә аңа зыян китереп түләүле уңайлыкларны күрсәтү ярамый.

3.4. Учреждение, уңайлыкны күрсәткәнче бер көннән ким калмыйча вакыт алдыннан Кулланучыны белдереп, уңайлыкны күрсәтү вакытын нигезле сәбәпләр буенча (каршы тора алмаслык көчле шартлар аркасында) күчерергә хаклы. Хәбәрләмә формасы уңайлыкны күрсәтү кагыйдәләре белән билгеләнә. Уңайлыкны күрсәтү вакытын күчергәне белән риза булмаганда алдан түләнгән, ләкин күрсәтелмәгән уңайлыкның бәясе Кулланучыга кире кайтарылырга тиеш.

3.5. Учреждениеләр Кулланучыларны күрсәтелә торган уңайлыклар турында түбәндәге ачык мәгълүмат белән тәэмин итергә тиеш:

- учреждение эше тәртибе;
- түләүле уңайлыкларны күрсәтү графигы;
- бәяләре билгеләнгән түләүле уңайлыкларның төрләре;
- түләүле уңайлыкларны күрсәтү һәм куллану шартлары;
- контрольдә тотучы органнар һәм оешмалар турында мәгълүмат.

3.6. Кулланучылар белән түләүле уңайлыклар өчен түләүләр касса контроле техникасын кулланып яисә төгәл хисап квитанциясе буенча кулдагы акча белән дә, учреждениеләрнең шәхси счетларына акчаларны күчерү юлы белән кулда булмаган акча расчеты белән дә билгеләнгән тәртиптә башкарыла.

3.7. Учреждениеләр түләүле уңайлыкларны мөстәкыйль рәвештә һәм (яисә) Россия Федерациясе законнарына туры китереп төзелгән килешү нигезендә башка бер шәхесләрне тартып (алар белән бергә катнашып) күрсәтә ала.

3.8. Учреждение түләүле уңайлыкларны күрсәткәндә аерым Кулланучылар категориясе өчен җиңеллекләр күрсәтелергә мөмкин. Җиңеллекләр Татарстан Республикасы норматив хокук актларына туры китереп Учреждение җитәкчесе боерыгы белән билгеләп куелалар.

3.9. Җиңеллекләр нигезендә күрсәтелә торган түләүе уңайлыклар турында мәгълүмат килүчеләр өчен Учреждение биналарының үтәрлек зоналарында урнаштырыла.

## 4. Түләүле уңайлыкларның бәяләрен (тарифларын) билгеләү тәртибе

4.1. Түләүле уңайлыкның исәп-хисабы һәм аның бәясен (тарифын) раслау "Гражданнарга һәм юридик затларга Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органы карамагындагы дәүләт бюджет учреждениеләре эшчәнлегенең төп төрләренә кергән уңайлыклар күрсәткән (эшләр башкарган) өчен түләү билгеләүнең якынча тәртибен раслау турында" 2010 ел 30 нчы декабрь Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына туры китереп башкарыла.

4.2. Учреждение түләүле уңайлыклар бәясен корып җибәрүченең функцияләрен һәм вәкаләтен башкара торган Татарстан Республикасы ГТХМ һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карамагындагы Татарстан Республикасы Икътисади һәм социаль тикшеренүләр үзәге ризалыгы буенча раслый.

## 5. Түләүле уңайлыкларны күрсәтүдән керемнәрне планлаштыру һәм куллану тәртибе

5.1. Түләүле уңайлыкларны күрсәтүдән керемнәрне планлаштыру учреждениенең күләм ягыннан күрсәткечләр нигезендә һәм шулай да Тәртипнең п. 4.1. туры китереп түләүле уңайлыкларның һәр билгеле төре буенча башкарыла.

5.2. Ел саен Учреждениеләр норматив хокук актлары белән билгеләнгән сроклар эчендә Татарстан Республикасы ГТХМ на киләсе финанс елга бюджет классификациясе киселмәсендә түләүле уңайлыкларны күрсәтүдән керемнәр алу прогнозын төзеп тапшыралар.

5.3. Түләүле уңайлыкларны күрсәтүдән алынган керемнәр 50% тан ким түгел күләмдә хезмәт өчен түләүгә, шул исәптән хезмәт өчен өстәмә түләү һәм Учреждение эшчеләренең стимуллаштыра торган характерлы түләүләргә юнәлә.

## 6. Түләүле уңайлыклар исәбен оештыру һәм түләүле уңайлыкларны күрсәтү буенча эшне контрольдә тоту

6.1. Учреждениеләр билгеләнгән тәртиптә түләүле уңайлыкларның бухгалтер, салым һәм статистик исәпләрен башкара.

6.2. Учреждениеләрнең түләүле уңайлыкларны күрсәтү буенча эше артыннан контрольне Татарстан Республикасы ГТХМ, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы һәм Учреждениеләр эше артыннан контроль һәм күзәтү буенча функцияләрне башкара торган башка органнар башкара.

6.3. Түләүле уңайлыкларны күрсәтү буенча Учреждениеләрнең эшен оештыру өчен җаваплылыкны Учреждение җитәкчесе алып бара.